| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2022 с. Сарманово № 73

2018 елның 04 апрелендәге 116 номерлы
Совет карары белән расланган
Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә
хезмәт өчен түләү буенча
бердәм тариф челтәре кагылмый торган
аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең
хезмәт өчен түләү шартлары турында
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын тәртипкә салу максатыннан, Сарман муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 4 апрелендәге 116 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә» түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта:

өченче абзацта «компенсация түләүләрен» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «һәм компенсация түләүләре турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 пунктта:

1 пунктчада «50» санын «8» санына алмаштырырга;

3 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкаларын» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктчада:

икенче абзацта «25» санын «5» санына алмаштырырга;

өченче абзацта «10» санын «2» санына алмаштырырга;

6 пунктчада:

өченче абзацта «35» санын «7» санына алмаштырырга;

бишенче абзацта «50» санын «10» санына алмаштырырга.;

8 пунктта:

беренче абзацта «(компенсация түләүләрен исәпкә алып)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктчада «тугыз айлык тариф ставкасы» сүзләрен «бер бөтен уннан сигез айлык тариф ставкасы сүзләренә алмаштырырга»;

3 пунктчада «өч айлык тариф ставкалары» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктчада «айлык тариф ставкасының 25 проценты күләмендә премияне исәпкә алып, ике айлык тариф ставкаларын» сүзләрен «бер айлык тариф ставкасы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Аерым оешмалар җитәкчеләренә аерым оешмалар хезмәткәрләренә өстәмәләр һәм башка түләүләр билгеләү турында элек чыккан актларны әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль район
Советы рәисе Ф. М. Хөснуллин